# Без Тукай нәселеннән



Һәр елны татар дөньясы шагыйребез Габдулла Тукай туган көнен билгели. Без дә “Тукайлы язлардан” читтә калмадык, 26 апрель көнне үзәк район китапханәсенә фәһемле сөйләшүгә җыелдык. Чараны район китапханәләр системасы директоры Рәвил Әхмәтов һәм шагыйрә Рафига Усманова алып бардылар.

Рәвил Гали улы Тукайның кыска гына, әмма авыр һәм истәлекле вакыйгаларга бай тормыш юлын кабат искә төшерде. Рафига Карам кызы исә үзенең бәләкәй Апушка, бөек Тукайга, аның әнисенә багышланган шигырьләрен укып ишеттерде, шагыйрьнең иҗатына соклануын белдерде.

Чараның икенче өлешендә Тукай сокланып өйрәнгән, иҗатында кулланган халык авыз һәм йола иҗаты, милли гореф гадәтләргә нигезләнеп төзелгән сценарий буенча (авторы Р.Усманова) Мулла авылының "Моңдарья" ансамбле (җитәкчесе З.Гыйлемшина) сәхнәләштереп күрсәткән халкыбызның күңел аклыгын, йөз сафлыгын, җаны пакълыгын символлаштырган ап-ак яулыгы, билендәге алъяпкычы, чиккән сөлгесенең кешенең гомер юлында туганнан башлап, бакыйлыкка күчкәнче тоткан роле турында шигырь, мәкальәйтемнәр, җыр-биюләр һәм милләтнең төрле йолалар, гореф гадәтләре белән үрелеп барган матур күренешләргә бай “Ак алъяпкыч билләрдә, чиккән сөлге иңнәрдә” дип аталган тамашасы күңелләрдә якты тәэсир калдырды. Бигрәк тә контракт белән махсус хәрби операциягә китүче егетне ак сөлгегә төрелгән икмәк каптырып, биштәренә кулъяулыкка салынган туган җир туфрагы, тастымалга төреп кечкенә Коръән салып, җиңү яулап, исән-сау кайтуын теләп озату күренеше тамашачыларның күзләрен яшьләндерде.

**Венера АРСЛАНОВА.**
**Эльвина РАЯНОВА фотосы.**



# Сарыкай гына бәпкәләр

Чебешләр бер урынга өелеп ятса, димәк, аларга җылы җитешми. Алар бер-берсен тапый, аста калганнарының хәле бетүе, тыны буылуы бар. Шуңа күрә, үсеп нығынып алганчы, кызыл лампа (инфракрасная лампа) куюә киңәш ителә.

Тавык чебешләре, каз бәпкәләре коры урынны ярата, үрдәк суга, дымга бирешеп бармый. Үрдәк бәпкәләренә җимне дә сулырак әзерләгез. Каз бәпкәләренә оеган сөт килешеп бетми, аларның азыгын әчемәгән сөткә болгатырга кирәк.

Зурайган (берничә атналык) чебешләр, бәпкәләр алсагыз, нәрсә ашап яшәгәннәр, шуны дәвам итегез, җайлап үзегезнең азыкка күчерегез. Сатуда бөтен төр ярмалар бар. Мәсәлән, каз, үрдәк бәпкәләре өчен бодай, солы һәм кукурузны вак итеп ярдырып әзерләгән катнашазык шәп булачак. Кошларның рационына витаминлы үләннәр – кычыткан, клевер, меңьяфрак һ.б. кертергә онытмагыз.

Чебешләр янында һәрвакыт ком һәм таза көл торсын. Көл тавык чебешләре, бройлерларга һәр төрле паразитларга каршы көрәш өчен кирәк, алар вакыты-вакыты белән көл ваннасы кабул итәргә тиеш.

**“Башкортстан календаре 2024”тән алынды.**